| | | |
|---|---|---|
| **УКАЗ**<br>ПРЕЗИДЕНТА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ПРЕЗИДЕНТЫ<br>**УКАЗЫ** |

# Татарстан Республикасының кайбер торак пунктлары территорияләрендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле кертелгән карантинны бетерү турында

Терлекләрнең котыру белән чирләвенең соңгы очрагыннан соң ике ай узуы, эпизоотиягә каршы һәм профилактик чаралар уздырылу белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $3^1$ статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. Терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле кертелгән карантинны бетерергә:

а) Татарстан Республикасының түбәндәге торак пунктлары территорияләрендә:

Бөгелмә районының Петровка поселогы;

Саба районынын Зур Кибәче авылы;

Чирмешән районының Саминовка авылы;

б) Татарстан Республикасының түбәндәге аерым территорияләрендә:

Казан шәһәренең Северный торак массивындагы Пришвин урамы;

Татарстан Республикасы Кукмара районының Зур Кукмара авылындагы Колхоз урамы;

Лаеш районының Усад авылындагы Дорожная урамы;

Саба районының Сатыш авылындагы Вахитов урамы;

Татарстан Республикасы «Арча урманчылыгы» дәүләт казна учреждениесенең Балтач участок урманчылыгындагы 94 нче квартал.

2. Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының кайбер торак пунктлары территорияләрендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2015 елның 1 июлендәге ПУ-611 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Кукмара районының аерым территориясендә терлекләр котыру авырулы булганга, аның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2015 елның 6 июлендәге ПУ-623 номерлы Указы.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2015 ел, 07 сентябрь
№ ПУ-835